

# Такташевские чтения

ПЕДАГОГ 13.РУ

Центр непрерывного повышения профессионального мастерства
педагогических работников – «Педагог 13.ру»

# ТАКТАШЕВСКИЕ ЧТЕНИЯ

*Сборник материалов
республиканской конференции учителей
татарского языка и татарской литературы,
посвященной творчеству татарского поэта
Мухамметхади Хайрулловича Такташева (Хади Такташа)*

Саранск
2022

ББК 83.3 (2Рос=Тат)
Т15

**Такташевские** чтения : сборник материалов республиканской
Т15 конференции учителей татарского языка и татарской литературы, посвященной творчеству татарского поэта Мухамметхади Хайрулловича Такташева (Хади Такташа) / сост.: Ф. Ф. Боярова. – Саранск : ЦНППМ «Педагог 13.ру», 2022. – 36 с.

Рекомендовано к печати редакционно-издательским советом
ГБУ ДПО РМ «ЦНППМ «Педагог 13.ру»

**ББК 83.3 (2Рос=Тат)**

© Боярова Ф. Ф., составление, 2022
© ГБУ ДПО РМ «ЦНППМ «Педагог 13.ру», 2022

***А. Ш. Абдюшева***,
*учитель татарского языка и литературы*
*МОУ «Аксеновская средняя общеобразовательная школа»*
*Лямбирского муниципального района*

# ТАТАР СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫ ҺАДИ ТАКТАШ

Һади Такташ (Мөхәммәтһади Хәйрулла улы Такташев) 1901 елның 1 январенда элекке Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва АССРның Торбеево районы) Сыркыды авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Кечкенәдән үк әдәбият укырга, җырлар, такмаклар чыгарырга һәвәс булып үсә. Башта ул үз авылларындагы мәктәптә укый, аннары аны заманына күрә укыту процессы яңачарак корылган, Сыркыдыдан утыз чакрым ераклыктагы Пешлә мәдрәсәсенә бирәләр. Шунда Һади 1911 елдан 1913 елның ахырына кадәр укый.

Беренче империалистик сугыш башланып, алты балалы зур гаиләнең матди хәле бермә-бер кыенлашкач, Хәйрулла абзый үзенең улларын читкә эшкә җибәрергә карар кыла. Шул җөмләдән унөч яшьлек Һадины да, үзләренә кардәш тиешле бер сәүдәгәргә ияртеп, Бохара шәһәренә озата. Һади әүвәл әлеге сәүдәгәрнең өендә хезмәтче малай хәлендә яши, аннары шәһәр байларыннан берсенең мануфактура кибетендә приказчик өйрәнчеге булып эшли. Хезмәттән буш вакытларында шәһәр яшьләренең төрле мәдәни эшләренә, һәвәскәрләр оештырган спектакль, концертларга актив катнаша һәм, бала чактан ук башланган әдәби иҗат тәҗрибәләрен дәвам иттереп, «Газраилләр», «Караңгы төннәрдә», «Төркстан сахраларында» исемле шигырьләрен яза. Болардан «Төркстан сахраларында» дигәне Ташкентта нәшер ителә торган «Олугъ Төркстан» газетасының 1918 ел 21 январь санында басылып та чыга. Бу — һ. Такташның матбугатта дөнья күргән беренче шигыре.

1918 елның көзендә Һади Такташ туган авылы Сыркыдыга кайта. Ләкин әдәби иҗат белән чиксез кызыксынган, үзлегеннән укып, белем дәрәҗәсен күтәрергә омтылган шагыйрь егет, авылда ел ярым чамасы китапханә мөдире һәм башлангыч мәктәп укытучысы булып эшләгәннән соң, яңадан урыныннан кузгала: 1919 елның көзендә Оренбургка китә. Монда ул Оренбург губкомы органы «Юксыллар сүзе» газетасында җаваплы секретарь булып эшли, политик курсларда укый, шәһәрнең мәдәни тормышында кайнап, Щ. Камал, А. Таһиров кебек күренекле язучылар белән таныша, үзе хезмәт иткән газета битләрендә көндәлек вакыйгаларга багышланган хәбәрләрен һәм шигырьләрен («Караңгы төннәрдә», «Ачлык патша», «Антым», «Айның нурлары арасында» һ. б.) бастыра.

1920 елда иген уңмау сәбәпле Идел-Җаек буйларында яшәү шартлары кыенлашкач, һ. Такташ, дусларының тәкъдиме белән, 1921 елның язында Ташкент шәһәренә күчә һәм «Белем йорты» исемле журнал редакциясендә җаваплы секретарь булып эшли башлый. Бер үк вакытта ул Төркстан эшче-диһкан коммунистлар университетында тел-әдәбият укыта.

Ташкент чоры (1921 – 1922) Такташ иҗат эшчәнлегенең тагы да активлашуы, шагыйрь буларак, иҗат йөзенең үзенчәлекле форма ала баруы белән характерлы. Ташкентта ул үзенең беренче дәвер әдәби эшчәнлегендә күренекле урын тоткан романтик әсәрләрен — эчтәлеге белән нигездә мифологик легендаларга нигезләнгән һәм мифологик, символик образлар аша кеше шәхесенең рухи хөрлеген данлаган, аны буып торган явыз көчләргә, дини хорафатларга, социаль гаделсезлеккә каршы ярсулы көрәш, гыйсъянчылык идеясен алга сөргән бер төркем шигырьләрен («Онытылган ант», «Күләгәләр», «Нәләт», «Таң кызы», «Урман кызы») һәм атаклы «Җир уллары трагедиясе»н иҗат итә.

1922 елның җәендә берничә ай Мәскәүдә яшәгәннән соң, һ. Такташ шул елның көзендә Казанга килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда төпләнеп кала. 1923 елда аның «Җир уллары трагедиясе» һәм башка шигырьләр» исеме белән беренче җыентыгы басылып чыга. «Җир уллары трагедиясе» шул ук елда сәхнәгә дә менә. Спектакльнең премьерасында Идея ролен Такташ үзе башкара.

Казанга килгәч, Такташ берникадәр вакыт татар театрында суфлер булып эшли, аннары «Чаян» (1923 – 1924), «Октябрь яшьләре» (1925), «Авыл яшьләре (1926) журналларында һәм 1926 елның октябреннән 1929 елның мартына кадәр «Азат хатын» журналы редакциясендә җаваплы секретарь вазифаларын башкара. 1929 елда ул яңадан «Чаян» журналы редакциясенә кайта һәм гомеренең ахырына кадәр шунда эшли.

Казанда 1922 – 1923 елларда язылган әсәрләрендә («Бакчачылар», «Мәңгелек әкият», «Урамда», «Гыйсъян», «Янар таулар», «Пасха чаңнары» һ. б.) поэтик фикерләүдәге элекке романтик гыйсъянчылык мотивлары әле дәвам итсә дә, 1923 ел ахырларыннан башлап, һ. Такташ иҗатында һәм язу стилендә тормышны реалистик сурәтләү тенденциясе көчәйгәннән-көчәя барып, шагыйрьне яңа иҗади ачышларга китерә. В. И. Ленинның вакытсыз үлеме тәэсирендә туып, тирән кичереш һәм фәлсәфи уйланулар рухында язылган «Гасырлар һәм минутлар» (1924) поэмасы, «Давылдан соң», «Сагыну җырлары», «Такташ шигырьләре» исемле җыентыкларында урнаштырылган лирик-публицистик шигырьләр һәм, ниһаять, яшьлеккә, мәхәббәткә, тормышның матурлыгына гимн булып яңгыраган «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927), «Алсу» (1929), «Мокамай» (1929) кебек лирик поэмалар Такташны егерменче еллар татар поэзиясенең алдынгы сафына чыгарып бастыра. Әдипнең популярлыгы искиткеч тиз үсә, ул халыкның уй-хисләрен, хыял-омтылышларын илһамланып җырлаучы трибун-шагыйрь булып таныла.

1930 – 1931 еллар дәвамында Һ. Такташ «Киләчәккә хатлар» исемле шигъри әсәре өстендә эшли. Ун хат итеп уйланылган һәм авторның чор турында, аның катлаулы иҗтимагый һәм әхлакый проблемалары, буыннар язмышы турында фәлсәфи фикерләрен гәүдәләндерергә тиешле бу киң колачлы лиро-эпик әсәр, кызганычка каршы, тәмамланмый кала: шагыйрь хатларның өчесен генә язып бетерә. Әмма шул язылган өлешләре белән генә дә, «Киләчәккә хатлар» поэмасы шагыйрь иҗатында гына түгел, бөтен татар

поэзиясендә яңа чорның, социалистик чынбарлыкның лирик эпосын тудыру, дагы иң уңышлы тәҗрибәләрнең берсе булып санала.

Газета-журнал редакцияләрендә озак эшләү әдипнең журналистлык талантын да ачып җибәрә. Заманның күп төрле актуаль темаларына багыщ, лап, ул дистәләрчә публицистик мәкалә, очерк һәм фельетоннар язып бастыра. Хикәя жанрында, әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә көчен сынап карый. 1980— 1983 еллар арасында Татарстан китап нәшрияты әдипнең барлык жанр әсәрләрен үз эченә алган өч томлык җыелмасын бастырып чыгарды.

Һади Такташ иҗаты — сугышка кадәрге чор татар совет поэзиясенең иң югары ноктасы. Әдип бөек революция һәм социализм төзү елларының кырыс романтикасын, шул чор кешеләренең рухи матурлыгын сәнгатьчә гәүдәләндергән төрле жанрдагы әсәрләре белән татар әдәбияты тарихында яңа сәхифә ачты, яңа принципларга таянган социалистик реализм әдәбиятының нигез ташларын салуда үзеннән зур өлеш кертте. Аның рухы, аһәңе белəв халыкчан поэзиясе, үзенә бер шигъри мәктәп тәшкил итеп, бик күп шагыйрьләрнең үсүенә, формалашуына зур уңай йогынты ясады һәм хәзер дә үзенең тәэсирен югалтмый саклап килә. Такташ традицияләрен өйрәнү, аның поэтика өлкәсендәге уңышлы тәҗрибәләрен иҗади үзләштерү бүген дә дәвам итә.

Һади Такташ 1931 елның 8 декабрендә Казанда вафат булды. Аның гәүдәсе Казанның М. Горький исемедәге Үзәк культура паркы территориясенә урнашкан Туганнар каберлегендә җирләнде.

## КЛАССИК ТАТАРСКОЙ СОВЕТСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ ХАДИ ТАКТАШ

Хади Такташ (Мухаметхади Хайруллович Такташев) родился 1 января 1901 года в селе Сыркыды Спасского уезда бывшей Тамбовской губернии (ныне Торбеевский район Мордовской АССР) в семье крестьянина среднего достатка. С раннего детства у него развивается страсть к чтению литературы, сочинению песен, частушек. Сначала он учился в школе в своей деревне, затем его отдали в медресе Пишляй в тридцати километрах от Сургодь, где со временем учебный процесс наладился по-новому. Учился там же с 1911 до конца 1913 года. С началом первой империалистической войны, когда материальное положение большой семьи с шестью детьми несколько осложнилось, Хайрулла абый решил отправить своих сыновей на работу за границу. В том же году тринадцатилетнего Хади отправили в Бухару в сопровождении одного из купцов. Хади сначала жил в доме этого купца в положении мальчика-слуги, затем работал учеником приказчика в мануфактурном магазине одного из городских богачей.

В свободное от службы время активно участвует в различных культурных мероприятиях молодежи города, любительских спектаклях, концертах и, продолжая начатые с детства литературные творческие опыты, пишет стихи «Газели», «В темные ночи», «В пустынях Туркестана». Из них «В

пустынях Туркестана” была опубликована в газете «Великий Туркестан», издававшейся в Ташкенте, в номере от 21 января 1918 года. Это первое стихотворение Хади Такташа, опубликованное в печати.

Осенью 1918 года Хади Такташ вернулся в родное село Сургодь. Однако поэт-юноша, безгранично интересовавшийся литературным творчеством и стремившийся к самообразованию, после полутора лет работы в деревне заведующим библиотекой и учителем начальной школы, вновь осенью 1919 года уехал в Оренбург. Здесь он работал ответственным секретарем органа Оренбургского губкома газеты «Слово башкир», учился на политических курсах, принимал участие в культурной жизни города, познакомился с такими известными писателями, как Ш. Камал, А. Тагиров, на страницах газеты, в которой он служил, публиковал свои рассказы и стихи, посвященные повседневным событиям: «В темные ночи», «Голодный царь», «Клятва», «Среди лучей Луны» и др.

Когда в 1920 году из-за неурожая условия жизни в Поволжье осложнились, Хади Такташ, по рекомендации друзей, весной 1921 года переехал в Ташкент и стал работать ответственным секретарем в редакции журнала «Дом знаний». Одновременно он преподавал язык и литературу в Туркестанском рабоче-крестьянском коммунистическом университете. Ташкентский период (1921 – 1922) характеризуется еще большей активизацией творческой деятельности Такташа, становлением его как поэта и обретением самобытных форм творчества. В Ташкенте он создал ряд романтических произведений, занимавших видное место в его литературной деятельности первого периода – ряд стихотворений («Забытая клятва»: «Тени», «Налят», «Дочь Зари», «Дочь леса»), основанных в основном на мифологических легендах и прославлявших через мифологические и символические образы духовное унижение человеческой личности, яростную борьбу с угнетающими ее злыми силами, социальной несправедливостью и продвигавших идею гуманизма.

Прожив несколько месяцев в Москве, летом 1922 года Хади Такташ приехал в Казань и обосновался там до последних дней своей жизни. В 1923 году вышел его первый сборник «Трагедия сыновей Земли» и другие стихотворения. «Трагедия сыновей земли» была поставлена на сцене в том же году. Роль Идеи на премьере спектакля исполнил сам Х. Такташ.

Приехав в Казань, Такташ некоторое время работал суфлером в Татарском театре, затем работал ответственным секретарем в журналах «Чаян» (1923 – 1924), «Октябрьская молодежь» (1925), «Сельская молодежь» (1926) и с октября 1926 по март 1929 года в редакции журнала «Азат хатын». В 1929 году он вновь вернулся в редакцию журнала «Чаян» и работал там до конца жизни.

***Н. И. Башмакова,***
*учитель татарского языка и литературы*
*МОУ «Болдовская средняя общеобразовательная школа»*
*Рузаевского муниципального района*

##ҺАДИ ТАКТАШ – МӘХӘББӘТ ҖЫРЧЫСЫ

Шундый шәхесләр була: аларга язмыш үзләре хезмәт иткән өлкәдә беренче булу вазифасын йөкли. Икенче төрле әйткәндә, әйдәп баручы була. Шуңа күрә андыйлар бик тиз вакыт эчендә баш әйләндергеч биеклекләргә ирешәләр, үз-үзләрен аямыйча янып эшлиләр, иҗат итәләр, җәмгыятьтә олы абруй казаналар. Һади Такташ кыска гына гомерендә бай рухи мирас калдырган шундый шәхесләрнең күренеклесе иде. Җирдә нибары утыз ел гына ел яши, үзе артыннан галәмәт бай мирас калдыру өчен гадәти кеше генә булу җитми торгандыр, аның өчен Такташ булу кирәктер.

“Яз шикелле саф, җәй кебек юмарт, йолдыз сыман якты бит ул безнең... Такташ”, – менэ шулай аның турында эйткән башкорт шагыйре Тимер Арслан.

Һади... Зәңгәр күзле Такташ. Сыркыды егете. Юк, гади егет кенә түгел Такташ. Ул бөтен барлыгы белән шигърият дөньясы.

Такташ үткән чор кешесе, егерменче еллар шагыйре генә түгел. Ул бөтен шигъри җаны белән безнең заман кешесе. Безгә «бәхет теләп, тәүфыйк теләп язган» сәлам хатлары безнең чорга да килеп иреште. Бүген да ул шигырьләре белән безнең сафта атлый, үткәндәге авыр көрәш юлын онытмаска искәртә; «Дөнья матур!» дип, шул матурлыкны күрергә, аның өчен көрәшергә өйрәтә.

Кеше өчен иң затлы,  бөек хис – яратуның серен әле тулысынча аңлата алучы булганы юк. Ләкин шунысы ачык: кешене кеше иткән нәрсә мәхәббәт. Аннан башка чын мәгънәсендә кешелекле, игелекле, башкаларны хөрмәт итүче, күңел нечкәлекләренә ия, назлы шәхес була алмый. Мәхәббәт – уңай хис, ә уңай хис кешене күркәм , матур итә. Ярату хисе балаларга, оныкларга күчә. Шул рәвешле, кеше гомере буе мәхәббәт белән бергә атлый. Аны картлык көннәренә кадәр саклаганнар гомерләрен мәгънәле үткәрдек дип әйтә алалар.Кешедә мәхәббәт хисләре елның теләсә кайсы вакытында туаргамөмкин. Такташ иҗатында мәхәббәт һәм яшьлек аерылгысыз темалар булып яши. Һади Такташ әдәбиятыбызга гүзәл әсәрләр бирде. Такташ – мәхәббәт җырчысы. Бу тема аның "Зәңгәр күзләр"ендә, "Таң кызы"нда, "Урман кызы"нда һәм башка бик күп әсәрләрендә чагыла.

Шулар арасында укучылар тарафыннан иң яратканы – “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасы булгандыр. Ул 1927 нче елда иҗат ителә. Поэманың сюжеты катлаулы тугел.Зөбәйдә белән Мәхмүт бер-берсен яратышалар. Егет кызга мөнәсәбәтендә бик ук житди түгел.Аны вакытны ләззәтле уздыру өчен генә кирәк дип карый. Зөбәйдә исә Мәхмүтне ихлас ярата.Шуңа күрә егеттәге хисләрнең чынлыгына да шикләнми. Халык әйткәндәй: мәхәббәтнең күзе сукыр. Нәтижәдә егет кызны алдый. Кыз балага узгач,туачак жан иясеөчен жаваплылыктан качып, Мәхмүт Зөбәйдә янына бэтенләй килмәскә уйлана. Бала

көткән ананың күңеле болай да бик нечкә була.Ата буласы егетнеңүзен ташлавы аны аеруча борчуга сала.Ләкин бала тугач, егеттәүз кылганнарына үкенү хисе уяна, ул Зөбәйдәсе һәм үзенең баласы янына килә. Гаилә түгәрәкләнә. Мәхәббәт алдауны,хыянәтне кабул итә алмый. Аның юлдашы – сафлык,тугрылык, намуслылык. Поэмада барлыгы укучыга әллә ни сизелми торган тагын бер образ бар. Ул – шагыйрьнең лирик образы.Әгәр ул булмаса, поэма болай жиңел укылмас иде. Әсәр бик матур өлештән башлана. "Мәхәббәт тәүбәсе" поэмасы күңелдә тирән эз калдыра. Татар шигъриятендә яшьлек һәм аның табигый юлдашы мәхәббәт турында кемнең дә булса мондый да матур, җыйнак итеп әйтеп биргәне юк дияргә мөмкин.

Яшьлек,
Гомереӊ кыска синеӊ,
Шундый кыска булып тоела,
Кичен чәчәк аткан була,
Ә таңында инде коела...
Мәхәббәт,
Ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта,
Тиле яшьлек ярты гомерен бирә
Аның хисе белән янарга...

Бу нәфис янгыраучы юллар укучының куңелен билгеле бер дулкынга көйли.

Шагыйрь Ана исемен бөек исем итеп саный, гаиләнең ныклыгын, бала тәрбияләүнең җаваплылыгын, аналарга хөрмәт белән карарга кирәклеген искәртә. Шул ук вакытта ике шагыйрь арасында ана булуга мөнәсәбәт, хатын-кызның яңа буынга җан бирү, бала үстерүгә карашларында аерма күзгә ташлана. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»ндәге ананы данлаган югары монолог һәркемгә мәгълүм:

Ана-
Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга;
Хатыннарның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке ана булуда...

Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» бугенге укучыны да тирән дулкынландыра.Еллар үткән саен, аның шигъри иҗатын һәр яңа буын үзенчә кабул итә, аннан үз рухына кирәкле азык таба. Шуңа күрә Һади Такташ бүген дә заманыбыз белән бергә атлый, аның көчле шагыйранә авазы, үткәннең ерак кайтавазы булып, кайнар рухлы шигырьләре аша безгә килеп ирешә.

Такташның безнең арадан киткәненә инде куп вакыт үткән. Ә ул әле һаман безнең күңелдә, халкыбыз күңелендә. Элеккечә уйчан, моңсу, элеккечә шаян, шундый ук көләч, мөлаем булып яшәвен дәвам итә. Аны якыннан белгән өлкән буын кешеләр өчен генә түгел, бүгенге яшь буын өчен дә Такташ

шундый ук кадерле, шундый ук якын. Халкыбыз йөрәгендә бөек Тукай шикелле мәңгелеккә урын алган шагыйрь ул Такташ.

Үләрмен дә онытырлар дип,
Юкка гына йөрәк янасың,
Тамбов урманнары сагыныр әле
Үзе үстергән бунтарь баласын, – дип язды.

Әйе, шагыйрь ялгышмады. Тамбов урманнары гына түгел, бик күп укучылары аны сагына. Такташ сагындыра.Халык үзенең сөекле шагыйрен һаман юксына:

Бәйрәмдә безнең тын табынга
Синең дә өлешең куела,
Беләбез - кайтмыйсың... шулай да
Кайтырсың шикелле тоела.

## Кулланылган әдәбият


1. Такташ Һ. Әсәрләр: 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010.
2. Гайфуллина, Ф. Һ. Такташ – мәхәббәт җырчысы / Ф. Гайфуллина // Мәгариф. – 2015.


## ХАДИ ТАКТАШ – ПЕВЕЦ ЛЮБВИ

Были такие личности, на которых судьба возложила обязанность быть первыми в той области, в которой они служили. Поэтому за короткий срок такие люди достигают головокружительных высот, самоотверженно трудятся, творят, пользуются большим авторитетом в обществе. Хади Такташ был одним из тех, кто за свою короткую жизнь оставил богатое духовное наследие. На земле он прожил всего тридцать лет, и для того чтобы оставить за собой богатое наследство, ему, наверное, недостаточно быть обычным человеком.

«Он у нас чистый, как весна, щедрый, как лето, яркий, как звезда... Такташ», – так говорил о нем башкирский поэт Тимур Арсланов.

Хади... Голубоглазый Такташ. Сын Сыркыды. Нет, не просто парень. Он – весь поэтический мир.

Такташ не только человек прошлого, поэт двадцатых годов. Он человек нашего времени со всей поэтической душой. До нашего времени дошли приветственные письма «…с пожеланием счастья». И сегодня он в стихах шагает в нашем строю, напоминая не забывать трудный боевой путь прошлого; «Мир прекрасен! Она научила меня видеть эту красоту, бороться за нее».

До сих пор не удалось в полной мере разгадать тайну самого прекрасного, величайшего чувства человека – любви. Но ясно одно: то, что делает человека человеком, – это любовь. Без него невозможно быть по-настоящему человечной, доброй, уважающей других, обладающей тонкостями души, нежной личностью. Любовь – это позитивное чувство, а позитивное чувство делает человека красивым, прекрасным. Любовь передается детям, внукам.

Таким образом, человек всю жизнь шагает вместе с любовью. Те, кто хранил его до глубокой старости, могут сказать, что провели жизнь осмысленно. Любовные чувства у человека могут возникнуть в любое время года. Неразделимыми темами в творчестве Такташа являются любовь и юность. Хади Такташ дал нашей литературе прекрасные произведения. Такаш – певец любви. Эта тема нашла отражение в его «Голубых глазах», «Дочери Зари», «Лесной деве» и многих других произведениях.

Среди них, пожалуй, самой любимой читателями была поэма «Покаяние любви», написанная в 1927 году. Сюжет поэмы несложен. Зубайда и Махмуд влюбляются друг в друга. Парень не очень серьезно относится к девушке. Он считает, что она нужна только для того, чтобы приятно провести время. Зубайда же искренне любила Махмуда, поэтому не сомневается в подлинности чувств парня. Как говорится в народе, у любви глаза слепы. В итоге парень обманывает девушку. После того, как девушка забеременела, сбежал от ответственности. Но после рождения ребенка у парня появляется чувство сожаления о содеянном, он приходит к Зубайде и своему ребенку.

В поэме есть еще один образ, который едва заметен читателю. Это лирический образ поэта. Если бы не он, поэма не была бы прочитана. Произведение начинается с очень красивой части. Поэма «Покаяние любви» оставляет глубокий след в душе. В татарской поэзии о молодости и ее естественном спутнике любви вряд ли кто-то когда-либо говорил так красиво и аккуратно.

***Ф. Ф. Боярова,***
*учитель татарского языка и литературы*
*МОУ «Черемишевская основная общеобразовательная школа»*
*Лямбирского муниципального района*

## ҺАДИ ТАКТАШ – ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНЕҢ АЛТЫН БАГАНАЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ

Дөрестән дә, егерменче гасырның давыллы вакыйгалары казанында кайнаган бу олы шагыйребез халык күңелендә мәңгегә урын алды.

Әдипләрне заман төрлечә сыный. Берәүләр вакыт сынавын үтә алмый, исемнәре дә, иҗатлары да дәвер капкасының үзләре яшәгән ягында гына торып кала. Икенчеләренең иҗаты исә халыкның рухи хәзинәсенә әверелеп, буыннан-буынга күчеп яши.

Һади Такташ иҗаты да менә шундый бәхетле язмышка очрады. Аның яшәү гомере дә, иҗат чоры да, еллар саны белән исәпләгәндә күп түгел. Әмма олы шәхесләрнең, бөек талант ияләренең тарихтагы һәм халык күңелендәге урыннары гомер озынлыгы һәм язган еллары саны белән исәпләнми. Аз яшәсә дә, шушы вакыт эчендә Һ.Такташ халкы һәм туган иле өчен күп эшләргә, бәяләп бетерә алмаслык кыйммәтле әдәби мирас иҗат итеп калдырырга өлгерде. Шуның белән ул татар халкының күңел түрендә Г. Тукай, М. Җәлил,

С. Сәйдәшев кебек бөек уллары белән янәшә урын алды.

Куактан куакка кунып, болын, урман-кырларның иркенлеген, гүзәллеген мактап җырлаган былбыл гына да түгел Һ.Такташ. Шигърият серләрен, халык поэтикасын соң нечкәлекләренәчә үзләштергән җырчы гына да түгел. Сирәк очрый торган хәзинәгә ия бәхетле шагыйрь генә дә түгел. Һ.Такташ– шәхес! Ул һәм аның иҗаты, барыннан да бигрәк, гадәттән тыш олы җанлы, киң күңелле, бар дөньяга гашыйк шәхес белән характерлана. Һәм нәкъ менә шул масштаблы шигъри шәхес булуы белән гыйбрәтле, яңадан-яңа буын шагыйрьләргә остаз булып торырга лаек.

Һади Такташ иҗаты – бай, өйрәнүне сорый торган күпкырлы иҗат. Аның тормыш һәм иҗат юлы әдәби тәнкыйтьтә инде шактый өйрәнелгән дә. Г.Галинең «Шагыйрь Һади Такташ турында» (1931), Г. Нигъмәтинең «Һади Такташ» (1932), Ш. Маннурның «Һади Такташ поэзиясе турында» (1940) кебек очеркларын, М.Маминның «Һади Такташ поэзиясе» (1952), Х.Хәйринең «Һади Такташ (Тормыш һәм иҗат юлы)» (1949), Х. Госманның «Такташ поэзиясе» (1958), Г.Халитның «Шагыйрь, чор, герой (Һади Такташ иҗатын өйрәнү тәҗрибәсеннән)» (1971) кебек монографик хезмәтләрен генә искә алсак та, күренекле шагыйрьнең иҗат һәм тормыш юлын өйрәнүгә багышланган шактый күп хезмәтләр барлыгы күренә. Тәнкыйтьчеләрнең күбесе аның поэзиясен анализлыйлар. Бу, билгеле, нигезле. Һ.Такташ –бәхәссез, иң элек шагыйрь, тик иҗатына бәя биргәндә, аның тәнкыйть мәкаләләренә дә игътибар итү сорала, чөнки ул хезмәтләр шагыйрьнең шәхесен тирәнрәк аңларга, аның карашларының киңлеген һәм эволюциясен тулырак ачарга булышалар. Һ.Такташның тәнкыйди чыгышлары, бер яктан, аның иҗатын тирәнрәк аңларга ярдәм итсә, икенче яктан, ул бу чыгышларында бүгенге көндә дә актуальлеген һәм кыйммәтен саклаган күзәтүләр һәм фикерләр дә табыла. Билгеле, аның тәнкыйть эшчәнлеген тикшергәндә аларның шагыйрь Һ. Такташ тарафыннан язылуларын да, шагыйрьнең шәхесе турында да исәпкә алырга кирәк.

Әдәби тәнкыйть — әдәби иҗатның бер төре, әдәби әсәргә һәм андагы тормыш күренешләренә бәя бирә , әдәби әсәрләрнең чынбарлык белән бәйләнешен өйрәнә. Матур әдәбиятның үсеш закончалыкларын билгеләү өчен, әдәби хәрәкәттәге тискәре, кире тенденцияләрне кире кагу максатыннан зәгыйфь, соры, эстетик кыйммәте түбән булган китапларны укучы арасына үткәрмәү юнәлешендә әдәби тәнкыйть зарур. Ул һәрвакыт үстерелеп торырга тиеш, чөнки әдәби тәнкыйть әдәби процесска , язучы иҗатына йогынты ясый, әдәби әсәрләрнең сәнгатьлелеген көчәйтүне, тормышка якынайтуны максат итә.

«Антик чорда ук аерылып чыккан әдәби тәнкыйть озак вакытлар үзенең әсәргә гомуми бәя бирү, авторны мактау яки хурлау, китапка рекомендация бирү мәгънәләрен саклап килә. Белинскийлар чорында исә әсәргә бәя аның идеяләре һәм образлары берлегендә бербөтен итеп карала, язучы иҗатына бәя язучының чорга, заман таләпләренә мөнәсәбәтеннән чыгып бирелә башлый.

Марксистик тәнкыйть әдәби әсәрне социаль, эстетик, этик күзаллаулардан чыгып карарга омтыла. Әдәби тәнкыйть, әдәби иҗат кебек үк, тормышны танып белү һәм аңа тәэсир итү чарасы булып тора.

Совет әдәбияты тәнкыйте художестволы әсәрләрне заманның иң әһәмиятле мәсьәләләре яктылыгында тикшерә һәм бәяли, аларда сурәтләнгән характерларның һәм тормыш күренешләренең ни дәрәҗәдә дөреслеген, язучы файдаланган сәнгатьчә сурәтләү чараларын ачып бирә.

## ХАДИ ТАКТАШ – ОДИН ИЗ ЗОЛОТЫХ СТОЛПОВ ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ

Действительно, этот великий поэт, воспетый в бурных событиях двадцатого века, навсегда занял место в сердцах народа. Время испытывает писателей по-разному. Одни не выдерживают испытания временем, и их имена и творчество остаются на той стороне ворот эпохи, где они жили. Творчество других стало духовным достоянием народа и передается из поколения в поколение.

Такая же счастливая судьба постигла и творчество Хади Такташа. Ни его жизнь, ни период творчества, судя по количеству лет, не велики. Однако места великих личностей, великих талантов в истории и в сердцах народа не учитываются продолжительностью жизни и количеством написанных строк. За это время Х.Такташ успел многое сделать для народа и своей Родины, создать неоценимое литературное наследие. Тем самым он занял место в душе татарского народа рядом с такими великими сыновьями, как Г. Тукай, М. Джалиль, С. Сайдашев.

Х.Такташ не только соловей, летающий от куста к кусту, он соловей, воспевающий простор, красоту лугов, лесов и полей. Он не только певец, который досконально освоил секреты поэзии, народную поэтику. Его творчество воспевается, прежде всего, необычайно жизнерадостной, великодушной, всепоглощающей личностью. И именно как масштабная поэтическая личность он достоин стать наставником для нового поколения поэтов.

Творчество Хади Такташа – богатое, многогранное творчество, требующее изучения. Его жизненный и творческий путь в литературной критике уже достаточно изучен (Г. Гали «О поэте Хади Такташе» (1931), Г. Нигматуллина «Хади Такташ» (1932), Ш. Маннур «О поэзии Хади Такташа» (1940), М. Мамин «Поэзия Хади Такташа» (1952); Х. Хайри «Хади Такташ (жизнь и творчество)» (1949), Х. Усманов «Поэзия Такташа» (1958), Г. Халит «Поэт, эпоха, герой...» (из опыта изучения творчества Хади Такташа). Если вспомнить только монографические труды, то видно, что существует немало трудов, посвященных изучению творчества и жизненного пути выдающегося поэта. Большинство критиков анализируют его поэзию. Это, конечно, обоснованно. Х. Такташ, бесспорно, прежде всего поэт, но при оценке его творчества следует обратить внимание и на его критические статьи, так как эти работы помогают глубже понять личность поэта, более полно раскрыть широту и эволюцию его взглядов.

Литературная критика – один из видов литературного творчества,

оценивает литературное произведение и явления жизни в нем, изучает связь литературных произведений с действительностью. Для определения закономерностей развития художественной литературы необходима литературная критика, направленная на отрицание негативных, отрицательных тенденций в литературном движении, недопущение к читателю книг, имеющих слабую, серую, низкую эстетическую ценность. Она должна постоянно развиваться, так как литературная критика оказывает влияние на литературный процесс, на творчество писателя, имеет целью усилить художественность литературных произведений, приблизить их к жизни.

Литературная критика, выделившаяся еще в античную эпоху, долгое время сохраняла смысл давать общую оценку своему произведению, хвалить или унижать автора, давать рекомендации к книге. В эпоху В. Г. Белинского же оценка произведения рассматривается в единстве его идей и образов, оценка творчества писателя начинает даваться исходя из отношения писателя к эпохе, требованиям времени. Марксистская критика стремится рассматривать литературное произведение исходя из социальных, эстетических, этических представлений. Литературная критика, как и литературное творчество, является средством познания жизни и воздействия на нее.

***С. Н. Ибрагимова,***
*учитель татарского языка и литературы*
*МОУ «Сабаевская средняя общеобразовательная школа»*
*Кочкуровского муниципального района*

## ХАДИ ТАКТАШ В МУЗЫКАЛЬНОЙ КУЛЬТУРЕ

Говорят, что татарская поэзия XX века стоит на трёх буквах «Т»: Тукай, Такташ, Туфан. С первой буквой всё вроде бы ясно – «в его поэзии живёт душа нашего народа», как сказал Минтимер Шарипович, а Шаймиев никогда не ошибается. Стихи второй буквы первый Президент Татарстана ещё школьником мог часами цитировать наизусть. А именем третьей не случайно названа малая планета, расположенная в двухстах пятидесяти миллионах километров от Земли: «его судьба – подвиг», – отчеканил Шаймиев.

Настала пора с увековечиванием трёх букв и в музыкальной культуре.

Габдулла Тукай ещё в 2006 году стал героем оперы Резеды Ахияровой «Любовь поэта». Сперва предполагалось, что произведение это будет компактным, уместится в один акт, но либреттист Ренат Харис аж в шести картинах рассказал незатейливую историю отношений поэта и Зайтуны Мавлютовой. Поскольку герои встречались всего пять раз, поэтому первая картина – предыстория их любви. К тому же к биографии поэта либреттист добавил несколько символических образов и пофилософствовал о смысле жизни, о таинствах чувств, об ответственности перед теми, кого впускаешь в своё сердце…

И вот в 2019 году наступает очередь второй буквы.

Но одноактная камерная опера в семи картинах о Хади Такташе – не байопик. Либреттист Рузаль Мухаметшин намеренно уходит от биографии поэта, назвав своё произведение в лучших традициях эссеистов «Мой Такташ». Мой. Понимаете? Не чей-нибудь ещё. И не реальный. А мой. Тот самый, что живёт только в моём мире грёз и любви.

«Это самый любимый мой поэт, – говорит он. – Я восхищался его произведениями с детства. Да и до сих пор читаю и перечитываю. И пытаюсь понять его мир. История, рассказанная в опере, – фантасмагория: умирающий поэт встречается с самим собой молодым и пытается понять смысл своей жизни».

Этот предсмертный бред и становится основой для очередной легенды о Хади Такташе. Отказываясь раскрывать все переплетения сюжета, автор бесконечное число раз повторяет, что такого Такташа мир ещё не знал.

Но у композитора Ильяса Камала свой Такташ.

«Я, конечно, старался приблизиться к мысли Рузаля, передать его замысел, – отстаивает он своё право на интерпретацию, – но моя музыка – это не только внутренний мир Такташа, но и отражение времени, в котором жил и творил поэт, и всех противоречий эпохи».

А отражать есть что: перелом эпох, на котором посчастливилось жить и творить Хади Такташу, – всегда столкновение мнений, поиск «правды жизни», многозначность любого факта и вечная незавершённость спора. Думается, что уже одним этим предлагаемый материал оперы может привлечь мыслящую аудиторию. «Мой» Такташ и «моя» эпоха перемен есть у каждого из нас. Для кого-то Такташ – попутчик советской власти, для кого-то советская власть – попутчик человеколюбца Такташа.

Удачна и выбранная авторами форма – одноактная фантасмагоричная опера как проникновение в психологию человека, способ осознания того, что, по формуле академика Владислава Лекторского, «мозг находится в мире, а мир находится в мозгу». Мы живём в том, что ощутили, поняли и приняли. Мы те, кем сами себя считаем. Мы всего лишь сумма своих поступков, которые, в свою очередь, отражение наших мыслей.

И в этом смысле «Минем Такташ» и не Хади Такташ вовсе, а то, что мы хотим считать Такташем. Это зеркало, отражающее нас самих.

***З. Х. Кильдеева,***
*учитель татарского языка и литературы*
*МОУ «Большеполянская средняя общеобразовательная школа»*
*Кадошкинского муниципального района*

## ПОЭТ НА ВСЕ ВРЕМЕНА

2022 елның беренче январендә якташыбыз, атаклы татар шагыйре, татар совет поэзиясенә нигез салган шагыйрьләребезнең берсе булган Һади Хайрулла улы Такташка 121 яшь тулды.

«Һади Такташның татар поэзиясенең үсешендә йогынтысы гаять зур. Такташ үзенчәлекле һәм кабатланмас шагыйрь. Аның поэзиясендә татар һәм рус фольклорының, Маяковский һәм Есенинның йогынтысы сизелә. Ләкин Такташ ияреп язучы түгел. Ул үзенә аерым юл салып баручы шагыйрь», – ди Леонид Мартынов классик язучы турында. Бу чыннан да шулай. Дөньяда бары тик утыз гына ел яшәсә дә, әдәбиятта мәңгелек урын алып тора.

Һади Хайрулла улы Такташның тормышына һәм эшчәнлегенә караган төп даталарга күз салыйк. 1901 ел, 1 январь Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордовия республикасының Торбеево районы) Сыркыды авылында туа. Башлангыч белемне әти-әнисеннән алгач, 1911 – 1913 елларда Пешлә (30 чакрым ераклыктагы) мәдрәсәсе шәкерте була. 1917 елда матбугатта беренче мәкаләсе басылып чыга. 1918 елның 21 гыйнварендә Ташкентта нәшер ителә торган «Олуг Төркстан» газетасында «Төркстан сахраларында» дигән беренче шигыре дөнья күрә. 1918 – 1919 елларда туган авылы Сыркыдыда башлангыч мәктәп укытучысы, китапханә мөдире, мәктәп советы әгъзасы булып хезмәт итә. 1919 (көз) – 1921 (яз) елларда Оренбург губкомы органы «Юксыллар сүзе» газетасының әдәби хезмәткәре, җаваплы сәркатибе-секретаре, вакытлы мөхәррире-редакторы булып та тора.

Нихаять, 1922 елның көзендә, Казанга килә. Татар театрында суфлер булып эшкә урнаша. Ә 1923 – 1924 елларда Һади Такташ «Чаян» журналының җаваплы сәркатибе, «Татарстан» газетасының әдәби хезмәткәре булып эшли. 1923 елда «Җир уллары трагедиясе» һәм башка ши-гырьләрдән торган беренче җыентыгы басылып чыга.

Төрле-төрле басмаларда хезмәт итүе белән бергә (1926-1929 елларда «Азат хатын» журналының җаваплы сәркатибе, 1929-1931 еллар - «Чаян» журналының җаваплы сәркатибе, «Яңалиф» журналының редколлегия әгъзасы), поэзиясенең чәчәк аткан вакытында, «Давылдан соң», «Сагыну җырлары», «Такташ шигырьләре» исемле җыентыкларында урнаштырылган лирик-публицистик шигырьләр һәм «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927), «Алсу» (1929), «Мокамай» кебек лирик поэмалары дөнья күрәләр.1931 елда «Һади Такташ әсәрләре» дигән тулы җыелмасының беренче томы басылып чыга.

Якташыбыз 1931 елның 8 декабрь көне тиф авыруыннан Казанда вафат була.

Һади Такташ турында замандашлары шулай дип язганнар. Нил Юзеев яза: «Такташ шигырьләре совет яшьләре йөрәгендә тирән тамыр җәйгән. Бәхетле яшьлек җырчысы, патриот-трибун шагыйрь бүген дә безнең белән кыю атлап бара, гүзәл җырлары белән яңа тормыш төзүдә катнаша». Ә Баязит Бикбай, башкорт язучысы болай ди: «Һ.Такташ... татар поэзиясендә бөтен бер дәвер ачкан кеше. Чын татар поэзиясен бөек Тукай тудырган булса, аның совет чорындагы югары күтәрелешен... Такташтан башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Ул-татар әдәбиятының совет чоры Тукае, аның горурлыгы... Башкорт шагыйрьләре дә Һ.Такташ алдында бик зур бурычлылар... Андый шагыйрьләр, М. Горький сүзләре белән әйтсәк йөз елга бер генә туалар».

Әгәр дә миннән: «Татар поэзиясендә шигъри дөнья төзегән шагыйрьләр кемнәр?» – дип сорасалар, мин берничә шагыйрьнең исемен атар идем, ләкин иң беренче булып – Такташны.

«...Чын шагыйрь булу - зур бәхет, ә халыкның Тукае, Такташы булудан да зур бәхет юктыр ул», – ди Ринат Харис. Менә тагы шундый фикерләр яши. «Такташ безнең поэзиягә әлегәчә күрелмәгән яңа һава, югары художестволы яңа иҗат Иделе булып килеп керде. Без аның беренче чор иҗатын коры социология сукасы белән бураздалап үтәбез. Такташның төп остазы – халык әдәбияты һәм безнең классика. Шулар белән бергә Гейне, Байрон, Пушкин, Блок, Есенин һәм Маяковский», – ди аның турында Хәсән Туфан.

***А. Ф. Муртазина,***
*учитель татарского языка и литературы*
*МОУ «Татарско-Тавлинская основная общеобразовательная школа»*
*Лямбирского муниципального района*

## БЕЗГӘ ТАНЫШ БУЛМАГАН ТАКТАШ
## НЕЗНАКОМЫЙ НАМ ТАКТАШ

*Кем син?*
*– Белмим.*
*Әллә күптән инде*
*Онтылган бер иске танышмы,*
*Әллә таныш түгел, оялмыйча*
*Елмаясың үтеп барышлый?...* – бу сүзләр Һади Такташның «Таныш түгел елмаючы» шигыреннән. Чыннан да, бу шәхеснең биографиясендә безгә билгеле булмаган кызыклы фактлар бармы?

Такташ тормышыннан берничә кызыклы фактлар китерәсем килә.

Һади ишле гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә. Гаиләдә алты бала була. Безнең республиканың Сыркыды авылында гап-гади крестьян гаиләсе. Кызганыч, үз республикабызда туган шундый Шагыйрь башлангыч белемен авыл мәдрәсәсендә ала, ләкин абыстайдан сабак алуы озакка сузылмый. Кечкенә Һади тәнәфес вакытында коега тимер чынаяк төшерә. Моның өчен Абыстай Һадины дуслары алдында орыша. Һади шунда ук «Иман шарты» китабын ертып ташлый һәм абыстайга йөрүдән туктый.

Укырга-язарга әнисеннән өйрәнә. Аннары мәктәпкә бара, ләкин әтисе мәктәп укытуы белән канәгать булмый, һәм Һадины 30 чакрым ераклыктагы Түбән Пешләй мәдрәсәсенә бирә. Биредә алдынгы фикерле укытучылар ярдәмендә шагыйрьнең дөньяга карашы киңәя. Ул шул ук вакытта остазлары яздырган «Тәрҗемән», «Вакыт», «Йолдыз», «Ялт-йолт» кебек басмалар белән танышып бара. Такташка институтта укырга хыяллана башлый. Бик тырышып укый. Күп кенә язучылар иҗаты белән таныша. Чордашлары аның Гейне шигырьләрен оригиналда укыганын хәтерли, С. Цвейг белән немец телендә аралашканын сөйлиләр. Гаиләсенә ярдәм итү теләге белән ул үсмер чагында

Бохарага чыгып китә. Ачлыктан интеккән чаклары да була. Такташ бик тиз мөселманнар өммәтенә кереп китә, актив тормыш алып бара. 15 – 16 яшь булуына карамастан, аңа хәйрия фонды акчасын ышанып тапшыралар, димәк, ихтирам казана.

1920 елда Төркестан Үзәк Башкарма Комитеты аерым эскадрон оештыра. Эскадронда төрле милләт вәкилләре була: руслар,үзбәкләр, төрекәннәр, башкортлар, кытайлар һәм дә татарлар. Эскадронга чит ил вәкилләрен каршылау, дәүләт өчен аеруча әһәмияткә ия булган йортларны саклау һәм сугышчан бурычлар да йөкләткәннәр. Бу эскадронда Һади Такташ та хезмәт итә. Ташкент тирәләренә килеп чыккан басмачлар төркемнәренә һөҗүм ясап, аларны тар-мар иткәннәр. Бу эшләрдән тыш Такташ стена газетлары чыгару, сугышчылар алдында газета-журналлардан мәкаләләр кычкырып уку белән шөгыльләнә булган. Шул арада үз шигырьләрен дә укый була.

Такташны сугышчылар бик хөрмәт итәләр, зурлыйлар. Дунганнар һәм төрекмәннәр Такташны олылап “муллахан” дип атый булалар.

Такташ һәрвакыт та сугышчылар янында була, алар белән бергә ашый, казармада йоклый. Эскадронда наданлыкны бетерү эшен дә Такташ үз өстенә ала. Кыска вакыт эчендә эскадронда бер дә укый-яза белмәгән кеше калмый. Командирлар өчен дә Такташ өчен дә бу бик зур шатлык була.

Мәскәүдә яшәгән вакытта Такташ төрле шагыйрьләрнең түгәрәкләренә йөри башлый. Аны барысы да кызыксындыра, бу аның үз-үзен эзләү вакыты. Владимир Маяковский белән дә ул аның түгәрәгендә очраша һәм аңа чын-чынлап гашыйк була. Башта әдәби кичәләргә бик канатланып йөри, ләкин берникадәр вакыт узу белән аның күңеле кайта. Ул Маяковскийның иҗтимагый позициясен кабул итми.

Такташның сөйләм стиленә Маяковский йогынты ясамаган дип әйтеп булмый. Алар икесе дә шагыйрь-трибуна. Зур аудиторияне авызларына каратып тора алганнар. Маяковский да, Такташ та яшьләрнең кумирына әверелә. Такташның икенче хатыны Гөлчәһрә сөйләвенчә, Такташ университет бусагасын үтү белән, аны сырып алганнар. Шигырь яза икән, икенче көнне үк аны яттан сөйләүче кешеләр барлыкка килгән, яшьләр аның әсәрләрен бер-берсеннән күчереп ятлаган. Күп шагыйрьләр үз иҗат җимешләрен сөйли белми, ә Ходай Такташка ораторлык талантын кызганмаган. Сәхнә осталары да аның алдында чыгыш ясарга кыенсынган.

Халыкка тәэсир итү көче Такташны Маяковский белән бер дәрәҗәгә куя. Ләкин аларның идеаллары, тормышка карашлары төрле. Маяковский система пәрәвезенә эләккән шәхес була, ә Такташ системага каршы көрәшә. Әйе, ул аңларга тели, системага яраклашырга тырыша, ләкин аның романтик күңеле бу кысаларга сыеша алмый, аның тыны кысыла. Большевиклар аны кабул итми, язарга, иҗат итәргә бирми, бастырмыйлар. Ә бу иҗат кешесе өчен үлемгә тиң.

Гадел Кутуй белән Такташ бик дуслар булган. Бервакыт Такташ Кутуйга: «Мин алдан үлсәм, син минем каберемә беренче уч туфракны салырсың, син үлсәң, мин салырмын», – дигән. Шулай килешеп калганнар да. Такташ белән Кутуй икесе бер кичне өйләнгәннәр: Такташ – Гөлчәһрәгә (Гөлчәһрә Хәмзина),

Гадел – аның Газзә (Газзә Бадамшина) исемле дус кызына. Такташның «Алсу» поэмасындагы Газзәгә. Ләкин озак тормаганнар. Газзә Мәскәүгә Гөлчәһрә янына китеп барган…

Такташ төрле уку йортларындагы укучы яшьләр белән аралашып, алар янында үзен бик гади тота булган, инде танылган шагыйрь булуына карамастан, бер дә һаваланмаган. Яшьләр аны шагыйрь булуы өчен генә түгел, нәкъ менә үзен алар белән тиң, гади тотуы, шаян, шат күңелле мәзәкчәнлеге, тапкырлыгы өчен дә яратканнар.

Һәм дә соңгысы: кайбер кешеләрнең сүзләре буенча, Такташ башкаларга карата “донослар” язмаган бердәнбер шагыйрь була. Аның үлеме турында ишетү белән өйләренә килеп җиткән НКВД хезмәткәре Такташ хатынына: “Ник елыйсың, ахмак? Үз өендә, үз ястыгында үлгәненә куан, без инде аңа эш кузгаткан идек”, – дип әйткән, имеш. ФСБ архивларында моңа кагылышлы документларны эзләп караганнар, ләкин Такташка бәйлеләренә артык кешене җибәрмиләр булса кирәк. Такташ документлары чыгу белән күп татар шагыйрь һәм язучыларының “кара” эшләре ачыкланачак.  Һади Такташның уллары гомер буе бер-берсе белән аралашмаган дип сөйлиләр. Татар зыялыларының трагедиясе – Такташ нәселе дә урыслаша.

## НЕЗНАКОМЫЙ НАМ ТАКТАШ

*Кто ты?*
*– Я не знаю.*
*Или уже давно забытый*
*Старый знакомый,*
*Или незнакомый,*
*Не стесняясь*
*Улыбаешься, мимо проходя?* – это слова из стихотворения Хади Такташа «Улыбающийся незнакомец». Действительно, в биографии этого человека есть интересные факты, которые нам неизвестны.

